Ринат Нуруллин

Альпинист үрмәкүчләр

**Шигъри башваткычлар**

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2008

УДК 821.512.145-1-93(793.7)
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Н90

Рәссамы

*Илдус Әҗемов*

**Нуруллин Р.Г.**

Альпинист үрмәкүчләр: шигъри башваткычлар / Ринат Нуруллин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 88 б. — 5000 д. — ISBN 978–5–298–01656–8

Китапта Ринат Нуруллинның шигырь белән язылган мавыктыргыч башваткычлары, логик табышмаклары, тапкырлык таләп иткән шарадалары урын алган. Алар балаларны эзлекле фикер йөртергә өйрәтәләр, зирәклекне арттырырга ярдәм итәләр.

УДК 821.512.145-1-93(793.7)
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978–5–298–01656–8

© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Нуруллин Р.Г., 2008

## АВТОРДАН

Без могҗизаларга бай чорда яшибез. Кешелек тарихы 35000 ел белән исәпләнелсә дә, иң зур техник ачышлар бары тик соңгы 100–200 ел дәверендә генә ясала. Беренче эчке янулы двигательне 1860 елда Бельгия инженеры Этьенн Ленуар уйлап таба һәм арбага урнаштыра. Шулай итеп, беренче автомобиль барлыкка килә. Абыйлы-энеле Райтлар төзегән очкыч 1903 елда уңышлы очышын башкара.

Хәзерге чорда кеше берничә сәгать эчендә Җир шарының теләсә кайсы ноктасына элгә ала. 1875 елда америкалы Александер Грейам Белл тарафыннан телефон уйлап табыла. Кем әйтмешли, без хәзер «чабата»ны яки кәрәзле телефонны колак янына китереп, әллә ничә чакрым ераклыкта булган туганыбыз яки дустыбыз белән аралаша алабыз. Мондый ачышларның исемлеген дәвам итәргә була, моның өчен аерым бер китап язарга кирәктер. Әмма сүз башка мәсьәлә турында. Ничек инде кешеләр 350 гасырдан артык көн күреп, могҗизалы ачышлар бары тик соңгы 100–200 елда гына ясалган?

Миңа калса, бу мәсьәләгә карата җавап бик тирәндә ятмый. Сернең ачкычы шунда ки, кешеләр белем туплап, ниһаять, фикер йөртергә өйрәнә киләләр. Димәк, баш миен эшләтә белүче, сорауларга дөрес һәм тиз җавап таба алучы гына заманның алгы сызыгында була ала. Әйе, мускулларны ныгыту өчен физзарядка кирәк булган кебек, баш миенә дә күнегүләр кирәк.

Әлеге китапта мондый күнегүләр тагын да кызыграк, нәфисрәк формада – шигырьләр рәвешендә бирелә. Шигырьләр эчендә табышмаклар, башваткычлар һәм төрле ребуслар яшерелгән. Китапта алар катлаулылыгы үсә бару тәртибендә урнаштырылган. Беренче шигырьдә бирелгән табышмакны чиштең исә, син бер

имтиханны тапшырдың дигән сүз. Димәк, син тагын да акыллырак булдың һәм тагын да катлаулырак мәсьәләдән курыкмыйсың инде. Алда сине янә яңа ачышлар көтә. Уңышлар телим сиңа, укучым!

## ҖИДЕ ТУГАН-ТУМАЧА

*(Такмак-табышмак)*

Атнада җиде туган —
Берсеннән-берсе уңган.
Базга төшеп, Дүшәмбе
Алып менгән бәрәңге.
Урап кайтып чишмәне,
Су китергән Сишәмбе.
Тырышкан Чәршәмбе дә:
Бәрәңгене әрчегән.
Пәнҗешәмбе табага
Аны ваклап тураган.
Чыралар телеп, Җомга
Ут кабызган утынга.
Кыздырып майда, Шимбә
Бәрәңгене пешергән.
Таба төбен кырдылар,
Мине дә чакырдылар.
Истән чыккан Якшәмбе,
Ә ул нәрсә эшләде?
Әзерләгән Якшәмбе
Табышмакның иң шәбен.
— Исемнәребездән, — ди, —
Уртак хәреф эзлә, — ди.
Ишеткәнемне сезгә
Түкми-чәчми җиткезәм.
Шул хәрефне табыгыз,
Миңа хатлар языгыз.

## ИСЕМЕМ ИСКИТӘРЛЕК!

Гәрчә мин кош булмасам да,
Оча беләм кош сыман.
Исемемдә бер иҗекле
Өч сүз бергә кушылган.

Беренче сүз — елгаларның,
Күлләрнең текә чиге.
Йөрәк куа икенчесен,
Тамырлардан күчереп.

Өченчесе, кешни-кешни,
Чаба иркен даладан.
Йә, кайсыгыз исемемне
Әйтеп бирер иң алдан?

**ЧАБЫШМАК ТАБЫШМАКЛАР**

**1**

Мыеклы да койрыклы,
Мендәр өстендә йоклый.

**2**

Кәләпүштән зур түгел,
Чәнечкеле сюртугы.

**3**

Су астында сытык баш,
Баш белән гәүдә тоташ.

**4**

Кешнәп-пошкырып чапкан,
Тимер туганын тапкан.

**5**

Ат кадәрле килендә
Сөт заводы билендә.

**6**

Безелдәвек мушкетёр
Биш килер һәм биш китәр.

**7**

Мөгезле йонлач шайтан
Яр буен урап кайткан.

**8**

Таң патшасы таҗ кигән,
Иртән: «Күкри күк!» — дигән.

**9**

Ике канатлы комган
Мамык шәлен ябынган.

**10**

Булмаса да ул аксак,

Бара суга аксаклап.

**11**

Нәни поезд шуыша
Үзе тишкән куыштан.

**12**

Гәүдәсе гүя сорау,
Томшыгы очлы борау.

**13**

Кәнфит кәгазе оча —
Чәчәкләргә кодача.

**14**

Урманда мең пәһлеван
Чүмәлә өеп куйган.

**15**

Бәйләнмәгән оеклар
Болында ятып йоклар.

**16**

Юлга чыккан иртән үк
Дүрт канатлы вертолёт.

**17**

Сөтле хайван — яртысы,
Яртысы — таң тамчысы.

**18**

Куак астында, абау,
Аунап ята тере бау!

**19**

Һәрвакыт алдан чабар
Иң сәләтле эзтабар.

**20**

Ширбәт-балга күргәзмә
Оештырган кәрәздә.

**21**

Сигез күзле Шәкүрә
Ефәк парашют үрә.

**22**

Артка таба тота юл
Ишкәк койрык, киләшчә кул.

**23**

Кочып камыш камылын,
Бакылдый су маймылы.

**24**

Дүрт аяклы себерке
Аучылардан элдертте.

## ТӘЛИНКӘЛЕ ӘКӘМӘТ

«Ноль»не белә, «бер»не белә —
Белә бары ике сан,
Әммә хисаплауга калса,
Җиңә сине — ярышсаң.

Аннан башка математик,
Тапса да бер хәйләсен,
Чишә алмый заман куйган
Катлаулы мәсьәләсен.

Химикның ярдәмчесе ул,
Физикның булышчысы.
Раслап аның уңганлыгын,
Кораблар айга очты.

Тәлинкәле үлчәү түгел,
Ләкин тәлинкәсе бар.
Тәлинкәсенә төялгән
Төрле-төрле уеннар.

Күп сөйләдем, соравымны
Җиткерергә дә вакыт:
Нәрсә турында сүз бара —
Бирегезче аңлатып?!

## РАЙОН ИСЕМЕ

Айкап йөрсәң тел диңгезен
Фикер ятьмәсе белән,
Могҗизалы сүзләр чыга
Тел диңгезе төбеннән!
Төскә кушсаң сыекчаның
Чәй кайната торганын,
Шулар янына өстәсәң
Мал-мөлкәт күп җыйганны,

Татарстандагы районның
Атамасын табарсың.
Ул районның исемен әйт,
Даны илгә таралсын.

**СҮЗ БОТКАСЫ**

Озын сүзнең кыскасы —
Авыз ит сүз боткасын.
Ботканың тәмле сүзе
Дүрт сүздән тора үзе.

Беренче сүз сыртына
Су сибә хортумыннан,
Ә икенчесе җиргә
Дагасы белән тибә.

Өченче сүз ишелгән
Өч йөз алтмыш биш көннән.
Дүртенче сүзме?.. Ансы
Әйбернең төп хуҗасы.

Сыймас димә кашыкка,
Серле сүзне ачыкла.
Булмаса, сора ярдәм
Марка сөючеләрдән.

**ТУҢДЫРМА**

Бик тәмле булса да катык,
Яратам туңдырманы.
Булсын гына — йөздән артык
Ашый алам мин аны.

Әбием пошаманлана:
— Салкын тияр, улым, — ди.
— Кызу-кызу ашаганда
Салкын тими ул, әби!

...Туңдырманы бер-бер артлы
Кабып йоту килешми —
Берсе беткәч, иң кимендә
Өч минут ял тиешле.

Туңдырмам эри башлады,
Әйтеп бир әле тизрәк:
Йөз эскимо ашаганда
Ничә минут ял кирәк?

**БҮРӘНКӘ БӘЯСЕ**

Бүре бөгә бүрәнкә,
Берсе тора дүрт тәңкә.
Бишәр бүрәнкә ясаткан
Бүрегә ике тәкә.

Һәр тәкәгә бүләккә
Бүре биргән бүрәнкә,
Бүтән бүрәнкәләр өчен
Хезмәт хакын түләткән.

Утыр әле түмгәккә,
Бер генә әйт, биш әйтмә:
Бүрегә ничә сум акча
Биргән икән һәр тәкә?..

## ШӨГЫЛЬ

Бездә хәлләр җәйдәгечә,
Сездә ничектер хәлләр?
Ишеткәннәремне сөйлим —
Телем очында Хәйдәр.
Әлсерәп печән чапмый ул,
Болында җыймый җиләк,
Авыр капчыклар ташымый,
Тегермәндә он иләп.
Камыр әвәләми Хәйдәр,
Пәрәмәч тә пешерми,
Ләкин тирәдәгеләргә:
— Җитди минем эшем, — ди.
Челтәр ятьмә тотып, Хәйдәр
Күбәләк кумый кырда,
Әмма вакыты һич калмый
Әкиятләр укырга.
Әлбәттә, сәгатьләрне ул
Әрәм итми зерәгә:
Әй көч түгә, әй тырыша —
Ярышка әзерләнә.
Хәрәкәттә — бәрәкәт, дип,
Һәрчак ул хәрәкәттә,
Күнеккәндә тәнәфес тә
Ясап тормый ул хәтта...
Әйтә алмассыңмы икән,
Җәй көннәрендә Хәйдәр
Нәрсә белән шөгыльләнә
Иртәдән кичкә кадәр?
Әгәр биргән соравыма
Җавап таба алмасаң,
Шигырьдәге булган барлык

«Ә» хәрефләрен сана.

**ҖӘЙНЕҢ КИБӘН ОЧЫ**

Житте җәйнең кибән очы —
Утыз беренче июль.
Кибән очы гына түгел,
Кошлар сайраган көй ул.

Юмарт җәйнең июль ае —
Бүләкләргә иң бай ай.
Көнләшер бу бүләкләргә
Хәтта үзе Кыш бабай.

Кыш бабайның Кар кызы бар —
Кабул ителгән шулай.
Әгәр Җәй әби табылса,
Булырмын Кояш малай.

Кояш малай урынында
Кар кызыннан калышмам,
Тәүге тапкыр әйтер идем
Сезгә мондый табышмак:

Бары тик бер хәреф кенә
Үзгәртеп һәр адымда,
Ничек итеп «КЫШ» сүзеннән
«ҖӘЙ» сүзен ясап була?..

Әйлән-бәйлән йөргән чакта
Алмагачлар тирәли,
Пешкән алма бирер иде
Жиңүчегә Җәй әби.

**ӘТИ КЫЗЫ**

Апам түгел ул миңа,
Сеңлем түгел ул миңа —
Унике яшь тулды бүген
Әтиемнең кызына.

Алмадылар инә дә,
Алмадылар дөя дә:
Туган көнгә иң шәп бүләк
Ул — энциклопедия.

Сезне сыныйсым килә,
Сездән сорыйсым килә:
Кем шул китапка шатлана,
Кем бу бүләккә ия?

## АЛЬПИНИСТ ҮРМӘКҮЧЛӘР

Эльбрусларга тиң тауларны
Яулаган үрмәкүчкә
Күп катлы биек йортларга
Менеп төшү ул пүчтәк!..

Сузып җебен, менде бүген
Җиденче катка кадәр
Үрмәкүчләрнең җитезе,
Әйтерсең лә каскадёр.

Ә артыннан үргә таба
Үрмәкүчнең малае
Үрмәләде, әй тырышты —
Тирләп чыкты маңгае.

Өченче катка җиткәч, ул
Туктады ял итәргә...
Шуннан нәрсәләр булганын
Сөйләрмен тик иртәгә.

Җиде үлчәп, бер кат кисеп,
Әйтеп бирмәссең микән:
Үрмәкүч малае җепнең
Күпме өлешен үткән?

## БОРЧА ҺӘМ БОРЫЧ

Борча борыч сатып алган,
Бер исни, бер төчкерә.
Төчкергәне ишетелми,
Чөнки борча кечкенә.

Төчкермәс иде дә, бәлки,
Борчаның борын сизгер —
Чирләр китә, гадәт китми,
Хет сикермә, хет сикер.

Бер төчкергәндә борчаның
Оча ярты борычы.
Борча, борыч оча диеп,
Томалый борын очын.

Серне күпме сакласаң да,
Барыбер ул ачыла —
Борча борычы оча дип,
Барча борча борчыла...

Борча биш тапкыр төчкерсә,
Шуны әйт син чамалап:
Сигез килограмм борычтан
Күпме борычы кала?

**БАКАЛАР КАЛА САЛА**

Билгеле ки, камыштан
Бакалар текми ыштан.
Камыштан бака халкы
Кора йорт һәм каралты,
Ясый читән коймасын,
Гаражын һәм башкасын.

...Бервакыт җыелышта,
Хәл итеп бертавыштан,
Карар кылды бакалар
Салырга Бакакала,
Сайлап куйдылар урын —
Күлнең камышлы кырын.

Бакалар аксакалы
Болай дип бакылдады:
«Сызганып куйсаң җиңне,
Кала төзү бик җиңел, —
Булсын гына тактасы,
Пычкысы һәм балтасы!

Бездә дәрт бар, көч-кодрәт —
Эш кораллары кирәк!
Иртәгә таң атуга
Йөз бака чумсын суга,
Тәүге чиратта алар
Алып кайтсын балталар!..»

Җикән җыеп кочакка,
Уйлан әле шул хакта:
Биш сәгатьтә биш бака
Таба алса биш балта,
Йөз бака йөз сәгатьтә
Ничә балта юнәтә?

**ТАШНЫ КАЯ ТАШЛАРГА?**

Тар тыкрыкта сукмакта
Галәмәт зур таш ята.
Һәркемгә бу таш киртә
Комачаулый, әлбәттә.

Әй хафалана халык:
«Булмый шул ташны алып,
Кәйлә белән дә ватып
Булмый — өслеге каты.

Тыкрык тар булганлыктан,
Сыймый анда автокран.
Ташны йолкып алырга
Керә алмый трактор да...»

...Кирәкми монда кәйлә,
Табыгыз берәр хәйлә.
Таш түгел, баш ватыгыз,
Сукмакны бушатыгыз.

## АЛМА АША, АЛМАШЫП

Өч дус кызның һәрберсендә
Өчәр алмасы булган.
Алмалары — тел йотарлык,
Бал-ширбәт белән тулган!

Һәр кыз, берәр алма биреп,
Дус кызларын сыйлаган.
Барлыгы кызларның тагын
Ничә алмасы калган?

## ТАТЛЫ ЙӨК

Чикләвек безнең якта
Бик күп була куакта.
Бар ризыкка карата
Чикләвекне ярата
Бала-чага да, карт та...

Әнә бүген дә Гата,
Атланып ак юртакка,
Урманнан кире кайта.
Чикләвек җыеп байтак,
Тутырган дәү рюкзакка.

Мактыйсың килсә, макта,
Мактарлык булган чакта:
Йөк кимесен дип атка,
Авыр рюкзакны Гата
Үз җилкәсенә таккан.

Урман урап арсак та,
Файдаланып форсаттан,
Сорап калыйм шул хакта:
Күрсәтелгән очракта
Җиңеләерме атка?

## ЭТ ТӨШЕ

Төш күрми димәгез этне,
Этләр дә төш еш күрә.
Авызына сөяк кабып,
Эт төшендә йөгерә.

Мондый сөякне моңарчы
Тапканы юк берәүнең:
Дөньяда иң һуш ислесе,
Дөньяда ул иң тәмле!..

Өч минут йокы саен эт
Күргән икешәр сөяк.
Төшкә йөз сөяк керсен дип,
Күпме йокларга кирәк?

## ОЗЫНБОРЫН ОНЫКЛАРЫ

— Кая болай, Озынборын,
Ашыгасың кичкырын?
Әллә инде эшсезлектән
Таба алмыйсың урын?

Бәллүр Канат бирде җавап,
Борын очын боргалап:
— Онықларымны сыйларга
Алып кайтамын салат.

Туксаннан ук артмаса да,
Җитмештән артык алар —
Балаларым саны хәтле
Һәр баламда бар бала!

...Шулай дигәч, Бәллүр Канат
Ашыгып очты кабат...
Аның ничә оныгы бар,
Әйтеп бир әле санап?!

## РОБОТ ЯСЫЙМ ДИСӘҢ...

Бар металлар арасыннан
Иң кулае — әлүмин,
Әлүминнән генә робот

Ясар идем әле мин.

Чакы-чокы итеп басып
Ул идән паркетыннан
Йөрер иде Айдан төшкән
Гуманоидлар сыман...

Физиканы яхшы белсәң,
Хыяллар чынга аша!
Син дә робот ясыйм дисәң,
Үзеңне күрсәт башта.

Йә, әлүмин тыгызлыгын
Белеп, санап бир әйдә:
Ике потлы робот өчен
Ул кирәк ни күләмдә?

## ПРОФЕССОР ЧӘҮКӘ

Ике өергә бүленеп,
Ун чәүкә очкан талдан.
Унберенчесе — профессор —
Болай уйланып калган:

«Ашыкмыйча ачыклыймчы,
Була аламы мөмкин —
Төркемнәрдәге кошларның
Аермасы бишкә тиң?»
...Галим чәүкә нидер яза,
Каләм очлап каурыйдан.
Аның нәрсәләр язганын
Күреп булмый кырыйдан.

Бәлки, син дә ак кәгазьне
Саннар белән бизәрсең,
Мөгаен, әйтеп бирерсең
Эзләнү нәтиҗәсен.

## УХАЛЫКМЫ БАЛЫК?

Су буеннан, арып-талып,
Балыктан кайта Талип.
Нәни көчеге йөгерә
Талиптан бераз калып.

— Ничә балык капты? — диеп
Кызыксындым тукталып. —
Эләктеме чуртан белән

Алабуга ухалык?!

Әйтеп бирәмени анык,
Балыкчы — сабыр халык:
— Тотканымның дүрттән өче
Һәм тагын тугыз балык!

...Балык санын саный-саный
Беттем инде буталып.
Саныйм дисәң, син дә сана,
Күнегүдән — осталык!

**НИ БӘЯДӘ?**

Хәниф килгән кибеткә,
Мөниф килгән кибеткә.
Компьютер өчен алмакчы
Алар CD-тәлинкә.

Хәнифнең — йөз сум җитми,
Мөнифнең — бер сум җитми,
«Капитал»ларын кушу да
Мәсьәләне хәл итми.

Башваткычның хәйләсен
Килә иде беләсем.
Кайсыгыз әйтә алыр соң
Тәлинкәнең бәясен?

**КАШЫК БУШМЫ?**

«Буран»нан «бура» бурыйлар,
«Карама»да «кар» ята.
«Бүрек»тә «бүре» утыра,
«Ат» сүзе бар «нарат»та.

«Тубал» тулы «бал» булганда,
Кашыклап аша балны.
Бал беткәнче әйтеп бирче,
Буш кашыкта аш бармы?

**БЕР АЙГА ЕЛ СЫЯМЫ?**

«Теләк» сүзенә «тел» кергән,
«Кояш» сүзенә – «оя».
Нинди ай эченә, әйтче,

Тулаем бер ел сыя?

**БЕР ОЛАУ СОРАУ**

Син текә дә, мин текә —
Атка печән кем кертә,
Кем малларны ашата,
Без текә булган чакта?!

Әйдә яшәмик әле
Текәлеккә текәлеп!
Кемдер эшләргә тиеш
Маңгай тирләгән килеш!

Хайван тормый бензин ашап —
Ашый печән, күши башак.
Кайрак тап, болынга чап,
Чалгы кайрап печән чап!

* * *

...Хисабетдин абзый иртән
Алып кайтты бер йөк печән.
Үзе атын тугара,
Үзе болай уйлана:

«Шушы печән Акбүземә
Җитәр иде берүзенә
Атна буе ашарга,
Ач йөрмәс ич бичара.

Танабыз да һава белән
Туенырга өйрәнмәгән,
Бер йөк печән танага
Җитә ике атнага.

Сарыгыма атап тотсам,
Үзе генә ашап торса,
Бу печән дүрт атнадан
Бетәр иде, фаразан.

Ашасалар барсы бергә,
Малларыма ничә көнгә
Олаудагы бар печән
Күшәргә җитәр икән?»

Җавап эзләп, такыр башын
Хисабетдин абзый кашый.
Әйдә, күрсәт текәлек —
Абзыйга булыш әле!

## ХАТ ТАШУЧЫ КӨНГЕРӘ

Сикергәләп көнгерә
Җилдән җитез йөгерә —
Почта ташып көн күрә.

Бар хатларны көнгерә,
Калдырмыйча төнгегә,
Таратырга өлгерә.

Ял иткән вакытында
Сорадым аннан:
— Кода!
Ничә хат бар сумкаңда?

Болай диде көнгерә:
— Хатлар саны бүленә
Төгәл итеп җидегә.

Ансат юлны сайласак
Һәм дүртәрләп санасак,
Бер хат артып калачак.

Башка төрле барласак,
Бишәрләп чутлап барсак,
Шулай ук арта бер хат.

Әгәр дә инде кабат
Санасак алтышарлап,
Сыңар хат артып кала.

...Китеп барды көнгерә,
Хатлар санын тик менә
Әйтеп бирер кем генә?

## ӘҮ!

Дүшәмбе бер гуманоид
Чит планетадан килгән.
Җирдәге хәлләрне күреп,
Кунагыбыз «Ә» дигән.

Сишәмбе көн гуманоид
Гөман иткән «ӘҮ» диеп,
Ә чәршәмбе «ӘҮҮӘ» әйтеп
Алган үзенчә биеп.

Пәнҗешәмбе гуманоид
«ӘҮҮӘҮӘӘҮ» дип көйләгән...
Шимбә көнне әфәндебез
Нинди сүзләр сөйләгән?

## **СУПЕРРЕБУС**

Якуб бирде бер ребус,
Чишә алмый йөрибез.
Дәфтәрдән куш бит йолкып,
Карандаш белән Якуб
Язды: $Я^3$ *= КУБ.*

— Монда һәр хәреф саен
Куегыз, — ди, — үз санын...
Ташладык футбол тубын,
Саныйбыз саннар кубын.
Ә нишли соң Якубың?!

Ә Якуб җиргә ятып
Хихылдый эче катып.
...Өметләр синдә, дустым! —
Бездә дә бәйрәм булсын,
Чиш Якубның ребусын.

## **ИЛӘК, ЧИЛӘК ҺӘМ КӨЯНТӘ**

Ике иләк ал кулыңа,
Чиләк тапмасаң әгәр.
Атың булмаса, суга бар,
Атланып көянтәгә.

Суны тутыра алмасаң
Сәнәк белән төяп тә,
Чишеп кара мондый ребус:
«*ИЛӘК* + *ЧИЛӘК* = *КӨЯНТӘ*».

Ребуска кергән сүзләрне
Алыштыр саннар белән,
Шул арада бер кашык су
Үзем кайтарып бирәм.

## **КАЯ ОЧАСЫЗ, КАЗЛАР?**

Киек казлар каңгылдашып
Кайталар җылы яктан.
Иң өлкән каз тәпиенә

Компаслы сәгать таккан.

Компас угына карый ул,
Сәгатькә күз салгалый:
— Сайлаган бер юнәлештә
Очыйк әле алга, — ди.

Кошлар төньяк-көнбатышка
Гел юл тотсалар әгәр,
Каз көтүе Җир шарының
Кай төшенә эләгер?

**ЭШЛЕКЛЕ БУЛСАҢ...**

Сездә борчак нихәтледер,
Бездә борчак бер кесә.
Башваткычтан баш ватылмый,
Авырта баш, бәрелсә.

...Колаклар шиңәрлек итеп,
Мактанчык чәчсен борчак.
Эшлекле булсаң, болай яз:
$УТ^2$ = *УЧАК*.

Язмадагы хәрефләрне,
Уздырып иләк аша,
Алыштырсаң цифрларга,
Менә булыр тамаша!

**РЕБУСЛАРНЫ НИЧЕК ТӨЗИЛӘР?**

Бәйнә-бәйнә сөйләп бирәм
Ничек ребус төзергә?
Моның өчен алдан кирәк
Бераз уйлап йөрергә.

Баш миендә фикер тугач,
Максатка бару ансат:
Ниятеңә керешәсең
«*Т*» хәрефеннән башлап.

Шуның янына өстисең
Бер кыска сүз, әйтик, «*АТ*».
«*ШАТ*» сүзен теркәп куясың,
Бу сүз үзе табышмак.
Монда шундый сорау туа:
Кем шат? Билгеле, шат ат!
Солыңны гына жәлләмә,

Туйганчы аны *АШАТ*.

Дәвам итеп булмый диеп,
Калмаска кирәк каушап. —
Атның хуҗасын искә ал,
Аның исеме — *РАШАТ*.

Бу сүзләрне бергә кушып,
Утыз меңгә тиң ясап,
Язып куясың ребусны:

*Т*
*А Т*
\+ *Ш А Т*
*А Ш А Т*
*Р А Ш А Т*

3 0 0 0 0.

Шуннан аңлатып китәсең
Төп шартын ребусларның —
Эзләп табарга кирәк дип
Һәр хәрефнең үз санын.

...Солысын ат ашый торсын,
Ихахай-михахайлап.
Шул арада ребусыңа
Үзең дә эзлә җавап.

**КОНСТРУКТОР КАРГА**

Кара тактада
Рәсем ясалган:
Чаба ак карга
Асма басмадан.

Чаба ашыгып
Озын басмадан,
Канат астына
Дәфтәр кыстырган.
...Карале, кара!
Мондый язма бар
Дәфтәр тышында:
«*ЧАБА* ґ *АК* = *КАРГА*».

Чаба ак карга,
Үзе уйлана:
— Кирәк язмага
Саннар куярга.

«*КАРГА*» сүзендә
Яткан санда болт
Ясарга тиеш
Бүген үк завод.

Ныгытыр идек
Асма басманы,
Шул болтлар белән
Боргычлап аны...

...Йә, күрсәт, энем,
Син дә тырышлык,
Табып бир әле
Тапкырчыгышны.

**БАС, КЫЗЫМ ӘПИПӘ!**

*(Такмак-табышмак)*

Бас, кызым Әпипә,
Син басмасаң, мин басам.
Әпипәнең табышмагын
Чишеп кара, ичмасам.

Бас, кызым Әпипә,
Ребусларга ни җитә!
Математик күнегүләр
Нейроннарны биетә.

«*БАС + КЫЗЫМ = ӘПИПӘ*»
Дип язылган ребуста.
Хәрефләрнең артларына
Цифрлар кереп поскан.

Бас, кызым Әпипә,
Санак төймәләренә.
Табышмакка җавабыңнан
Зирәклегең күренә.

**КЫРЫК КАРАК ӘКИЯТЕ**

Кырык карак әкиятен
Кайсыгыз укымаган,
Телевизордан кайсыгыз
Мультигын карамаган!
Хәзинәләр читтә торсын,
Ял итсен кырык карак,
Табышмагым әкияттән
Тагын да кызыклырак.

Җавабын таба алмассың
«Сим-Сим, ачыл!» дип кенә,
Чөнки яңа код куелган
Мәгарә ишегенә.
«*КЫРЫК + КАРАК = ӘКИЯТЕ*»
Тигезлегендә ята
Һәр хәрефкә туры килгән
Цифрлар яңа кодта.

Табышмакны әзерләдем
Бары тик сиңа атап,
Белем дөньясына илткән
Капканың ачкычын тап.

Мәгарәдәге җәүһәрләр
Тиң булса иде әгәр
Баш эшләтеп, хезмәт түгеп
Яуланган хәзинәгә!!!

## ЧӘҮКӘ КУНГАН ТҮБӘГӘ

Чәүкә кунган түбәгә,
Калаена чүгәләп.
Утырмас иде чүгәләп —
Дөньялары түгәрәк.

Чәүкә кунган түбәгә,
Күз төшергән түбәнгә.
Асфальтка язып куелган:
«*ЧӘҮКӘ + КУНГАН = ТҮБӘГӘ*».

Текә безнең чәүкә дә —
Шалтыраткан Мәскәүгә
Кәрәзле телефоныннан
Икенче бер чәүкәгә.

— Менә шундый язмада
Кирәк, — ди, — цифрларга
Хәрефләрне мач китереп,
Тигезлекне расларга...

Тегесе бу чәүкәгә
Җибәргән рәсми кәгазь.
Ул кәгазьнең эчтәлеген
Әйтә алмыйм, күрмәгәч.
Чәүкәдән белешегез

Йә үзегез чишегез —
Әйтегез, нинди саннарга
«*ТҮБӘГӘ*» сүзе тигез?

## МАЙМЫЛ ЯРАТА БАНАН

Маймыл ярата банан.
Мин дә ким түгел аннан,
Мин дә яратам банан.
Һич тә сөйләмим ялган —
Яратмас идем банан,
Тәмлерәк ул суганнан.

Әйе! Сөйләмим ялган,
Маймыл тезгән бананнан:
«*МАЙМЫЛ – ЯРАТА = БАНАН*».
Укымышлы ул булган —
Хәрефләр цифрлардан
Торганын әйткән алдан.

...Иң шәбен ребуслардан
Чишеп кара, юраман.
Җавап тапсаң, берзаман,
Бәлки, бирермен суган.
Юк! Суган түгел — банан!..
Банан түгел — барабан!!!

## ХИСМӘТНЕҢ ХИКМӘТЛӘРЕ

### Чатан пират

Әллә инде тимер казык,
Әллә чатан атаман,
Әллә пират бер аяклы
Басып тора тактада.

Хисмәт чүкеч белән бәрә
Аның эшләпәсенә,
Суккан саен чатан пират
Һаман тирәнрәк сеңә...

Нинди эш башкара Хисмәт,
Нәрсә икән ул пират? —
Әйтеп бир әле шуларны,
Әгәр булсаң син ир-ат!

### Ертык юрган

Ак юрганда ике такта,
Һәр аяк һәр тактада.
Хисмәт, ике таяк болгап,
Юрганны ертып чаба.

Ямаучы ямый юрганны,
Яңа тукыма өстәп...
Шушы чорда агачларда
Яфраклар нинди төстә?

**Яшел бүкән**

Иптәше бүләк иткән
Хисмәткә яшел бүкән.
Яшел бүкән кечкенә,
Сыртында чәнечкеләр.
Су сипсәң, бүкән үсә,
Су сипмәсәң дә түзә.
Уйлама бу керпе дип,
Керпе яшел булмый бит.
Алай да яшел бүкән
Нинди гөл булыр икән?

**Карбыз кыры**

Ике төркем малайлар
Кырда уңыш җыялар.
Чабыша алар тыз-быз,
Тәгәрәтәләр карбыз.

Хисмәт кенә йөгерми,
Капка алдында йөри...
Күн карбызны ятьмәгә
Нигә Хисмәт кертмәгән?

**ЧИШҮ ЫСУЛЛАРЫ ҺӘМ ҖАВАПЛАР**

**Җиде туган-тумача**

*Җавабы*: Барлык көн исемнәрендә «м» хәрефе бар.

**Исемем искитәрлек!**

*Җавабы:* Беренче сүз — «яр», икенче сүз — «кан», өченче сүз — «ат».
Бу өч сүзне берләштерсәң, «ярканат» сүзе килеп чыга.

**Чабышмак табышмаклар**

*Җаваплары*: 1 — песи; 2 — керпе; 3 — камбала; 4 — ат; 5 — сыер; 6 — озынборын; 7 — кәҗә; 8 — әтәч; 9 — каз; 10 — үр- дәк; 11 — суалчан; 12 — тукран;

13 — күбәләк; 14 — кырмыскалар; 15 — сарык; 16 — энә карагы; 17 — сыерчык; 18 — елан; 19 — эт; 20 — бал корты; 21 — үрмәкүч; 22 — кысла; 23 — бака; 24 — төлке.

**Тәлинкәле әкәмәт**

*Җавабы*: Компьютер.

**Район исеме**

*Җавабы*: Ак + су + бай = Аксубай.

**Сүз боткасы**

*Җавабы*: Фил + ат + ел + ия = филателия.

**Туңдырма**

*Җавабы*: 297 минут.

**Бүрәнкә бәясе**

*Җавабы*: Һәр тәкә 4 бүрәнкә өчен генә акча биргән яки 16 сум түләгән.

**Шөгыль**

*Җавабы*: Йөз «ә» — йөзә.

*«Ә» хәрефләрен санаучыга ярдәмлек.*

| Шигырь юллары | «Ә» хәрефләренең саны |
| --- | --- |
| БЕЗДӘ ХӘЛЛӘР ҖӘЙДӘГЕЧӘ, | 6 |
| СЕЗДӘ НИЧЕКТЕР ХӘЛЛӘР? | 3 |
| ИШЕТКӘННӘРЕМНЕ СӨЙЛИМ — | 2 |
| ТЕЛЕМ ОЧЫНДА ХӘЙДӘР. | 2 |
| ӘЛСЕРӘП ПЕЧӘН ЧАПМЫЙ УЛ, | 3 |
| БОЛЫНДА ҖЫЙМЫЙ ҖИЛӘК, | 1 |
| АВЫР КАПЧЫКЛАР ТАШЫМЫЙ, | 0 |
| ТЕГЕРМӘНДӘ ОН ИЛӘП. | 3 |
| КАМЫР ӘВӘЛӘМИ ХӘЙДӘР, | 5 |
| ПӘРӘМӘЧ ТӘ ПЕШЕРМИ, | 4 |
| ЛӘКИН ТИРӘДӘГЕЛӘРГӘ: | 5 |
| — ҖИТДИ МИНЕМ ЭШЕМ, — ДИ. | 0 |
| ЧЕЛТӘР ЯТЬМӘ ТОТЫП, ХӘЙДӘР | 4 |
| КҮБӘЛӘК КУМЫЙ КЫРДА, | 2 |
| ӘММА ВАКЫТЫ ҺИЧ КАЛМЫЙ | 1 |
| ӘКИЯТЛӘР УКЫРГА. | 2 |
| ӘЛБӘТТӘ, СӘГАТЬЛӘРНЕ УЛ | 5 |
| ӘРӘМ ИТМИ ЗЕРӘГӘ: | 4 |
| ӘЙ КӨЧ ТҮГӘ, ӘЙ ТЫРЫША — | 3 |
| ЯРЫШКА ӘЗЕРЛӘНӘ. | 3 |
| ХӘРӘКӘТТӘ — БӘРӘКӘТ, ДИП, | 7 |
| ҺӘРЧАК УЛ ХӘРӘКӘТТӘ, | 5 |
| КҮНЕККӘНДӘ ТӘНӘФЕС ТӘ | 5 |
| ЯСАП ТОРМЫЙ УЛ ХӘТТА... | 1 |
| ӘЙТӘ АЛМАССЫҢМЫ ИКӘН, | 3 |

| | |
|---|---|
| **ҖӘЙ КӨННӘРЕНДӘ ХӘЙДӘР** | **5** |
| **НӘРСӘ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНӘ** | **5** |
| **ИРТӘДӘН КИЧКӘ КАДӘР?** | **4** |
| **ӘГӘР БИРГӘН СОРАВЫМА** | **3** |
| **ҖАВАП ТАБА АЛМАСАҢ,** | **0** |
| **ШИГЫРЬДӘГЕ БУЛГАН БАРЛЫК** | **1** |
| **«Ә» ХӘРЕФЛӘРЕН САНА.** | **3** |
| БАРЛЫГЫ: | 100 |

**Җәйнең кибән очы**

*Җавабы*: Сүздән сүзгә күчеп мондый адымнар ясыйбыз:
КЫШ ® КЫЛ ® КӨЛ ® КӨЙ ® ҖӨЙ ® ҖӘЙ.

**Әти кызы**

*Җавабы*: Әтиемнең кызы ул — мин!

**Альпинист үрмәкүчләр**

*Җавабы:* Үрмәкүч малае җепнең өчтән бер өлешен үткән.

**Борча һәм борыч**

*Җавабы*: Чирек килограмм.

**Бакалар кала сала**

*Чишү ысулы*:

Һәр сәгать саен биш бака берәр балта табып тора. Ә йөз бака бер сәгать эчендә 20 балта таба алыр иде. Димәк, йөз сәгатьтә йөз бака 100 ґ 20 = 2000 балта таба ала.

*Җавабы*: 2000 балта.

**Ташны кая ташларга?**

*Җавабы*: Чокыр казып, ташны шул чокырга төртеп төшерергә һәм чокырны күмеп җир өстен тигезләргә кирәк.

**Алма аша, алмашып**

*Җавабы*: Өч алма.

**Татлы йөк**

*Җавабы*: Атка төшкән йөкнең күләме кимеми.

**Эт төше**

*Җавабы*: 2,5 сәгать.

**Озынборын оныклары**

*Чишү ысулы*:

Озынборынның балалары санын $x$ аша билгеләсәк, аның оныклары саны $x^2$ була. Бары тик $x^2 = 81$ саны гына 70 белән 90 аралыгына керүенә игътибар итеп, җавапны ачыклый алабыз. Озынборынның тугыз баласының тугызар баласы бар.

*Җавабы*: Озынборынның 81 оныгы бар.

**Робот ясыйм дисәң...**

*Чишү ысулы*:

Алюминийның тыгызлыгы $r = 2700$ кг/м$^3$. Бер пот — 16,38 кг. Ике потлы роботның массасы $m = 32{,}76$ кг. Роботны ясау өчен кирәк булган алюминийның күләме:

$V = m : r = 32{,}76 : 2700 = 0{,}012133$ м$^3$ (ягъни $V = 1{,}2133$ см$^3$).

*Җавабы*: 0,012133 м$^3$.

**Профессор чәүкә**

*Чишү ысулы*:

Беренче төркемдәге кошларның санын $x$ һәм икенче төркемдәге кошларның санын $y$ аша билгелибез. Шигырьдәге мәгълүматларга таянып, мондый тигезләмә системасын төзи алабыз:

$x + y = 10$
$x - y = 5$

Системадагы икенче тигезләмәдән: $x = y + 5$. Бу аңлатманы беренче тигезләмәгә куябыз: $y + 5 + y = 10$; $2y = 5$; $y = 2{,}5$ һәм $x = 2{,}5 + 5$; $x = 7{,}5$

Төркемнәрдәге кошларның саны натураль сан булырга тиеш. Димәк, кошлар саны буенча мондый нисбәттә булган төркемнәргә чәүкәләр бүленә алмыйлар.

*Җавабы:* Мөмкин түгел.

**Ухалыкмы балык?**

*Чишү ысулы*:

Балыкларның санын ачыклау өчен мондый тигезләмә төзелә:

$34x + 9 = x$. Моннан: $3x + 36 = 4x$ һәм $x = 36$.

*Җавабы*: Талип 36 балык тоткан.

**Ни бәядә?**

*Чишү ысулы*:

CD-тәлинкәнең бәясен $T$, Хәнифтә булган акчаны $X$, Мөнифтә булган акчаны $M$ аша билгелибез. Мәсьәләнең шартлары буенча CD-тәлинкәнең бәясе йөз сумнан да ким түгел, яки $T$   100.

Ике тигезләмә яза алабыз:

$T - X = 100$;

$T - M = 1$.

Бу тигезләмәләрдән:

а) Хәнифтә булган акча $X = T - 100$;

ә) Мөнифтә булган акча $M = T - 1$;

б) икесенең акчасы $X + M = 2T - 101$.

Ләкин шигырьдә әйтелгәнчә, $X + M < T$. Шулай итеп,

$2T - 101 < T$; $T - 101 < 0$; $T < 101$.

*T*   100 булуын исәпкә алып, җавапны табабыз: $T = 100$; $X = 0$; $M = 99$.

*Җавабы*: Тәлинкәнең бәясе — 100 сум. Башваткычның хәйләсе — Хәнифнең бер тиен дә акчасы булмавында.

**Кашык  бушмы?**

*Җавабы*: «Кашык» сүзе эчендә «аш» сүзе бар.

**Бер  айга  ел  сыямы?**

*Җавабы*: Апрель ае исеменә «ел» сүзе керә.

**Бер олау сорау**

*Чишү ысулы*:

Бер йөк печәннең күләмен *G* дип билгелибез. Атна 7 көннән торуын истә тотып, 1 көнгә һәртөрле хайван 1 йөк печәннең күпме өлешен ашаганын исәплибез:

ат — *G*  7 ; тана —  *G*14; сарык — *G*28.

Хайваннар барысы бергә 1 көндә печәннең $G_1$ = *G*7 + *G*14 + *G*28 =

= *G*4 өлешен ашыйлар, яки 1 көндә олаудагы печән күләменең

чиреге бетә. Димәк, ат, тана һәм сарык 1 йөк печәнне бергәләп 4 көндә ашап бетерә.

*Җавабы*: Хайваннар барысы бергә 1 йөк печәнне 4 көндә ашап бетерә.

**Хат ташучы көнгерә**

*Чишү ысулы*:

Хатлар санын белер өчен 7 гә бүленә торган $(x + 1)$ санны табарга кирәк. Биредә *x* үз нәүбәтендә калдыксыз 4 кә, 5 кә һәм 6 га бүленә торган сан. Аның иң кечкенә кыйммәте:

*x* = 3 ґ 4 ґ 5 = 60.

Шушы санны бөтен саннарга тапкырлаганда, башка кыйммәтләр тезмәсен алып була: 120, 180, 240, 300, 360, ...

$(x + 1)$ аңлатмасы үз чиратында 61, 121, 181, 241, 301, 361, ... кыйммәтләрен кабул итә. Бу саннар арасыннан 7 гә бүленә торганын табуы кыен түгел. Ул сан — 301. Димәк, көнгерәнең сумкасында иң кимендә 301 хат бар.

Әлбәттә, искә алынган саннар арасында 7 гә бүленә торганнары башкалары да бар, мәсәлән, 721. Аннан зурракларын да табарга була. Ләкин бу кадәр хатларны таратып бетерер өчен көнгерәгә бер көн генә җитмәскә мөмкин. Әйтик, эш көне 8 сәгать булса, 721 хатны адресатка җиткерү өчен сәгатенә 90 хат таратырга кирәк. Шулай итеп, җавапта иң кече сан кабул ителсә, дөрес була.

*Җавабы*: 301 хат.

**ӘҮ!**

*Чишү ысулы:*

Гуманоидның һәр көн әйтелгән сүзен урталай аерып тикшерик. Сүзнең беренче яртысы алдагы көн әйтелгән сүз белән тулысынча туры килә. Сүзнең икенче яртысы аның беренче яртысындагы «Ә» белән «Ү» хәрефләрен үзара урыннарын алыштырып төзелгән.

Шулай итеп, гуманоидның әйткәннәре:

дүшәмбе — Ә,

сишәмбе — ӘҮ,

чәршәмбе — ӘҮҮӘ,

пәнҗешәмбе — ӘҮҮӘҮӘӘҮ,

җомга — ӘҮҮӘҮӘӘҮҮӘӘҮӘҮҮӘ,

шимбә — ӘҮҮӘҮӘӘҮҮӘӘҮӘҮҮӘҮӘӘҮӘҮҮӘӘҮҮӘҮӘӘҮ.

**Суперребус**

*Чишү ысулы*:

*1 нче адым. КУБ* — төрле цифрлардан торган өч урынлы сан, димәк,

102 *КУБ* 987.

Моннан, бер урынлы сан буларак, 5 *Я* 9.

2 *нче адым. КУБ* саны төрле цифрлардан торуын искә алганда, ребус шартларына бары тик *Я* = 8 очрагы туры килә.

*Җавабы*: $8^3$ = 512.

**Иләк, чиләк һәм көянтә**

*Чишү ысулы*:

1 нче адым. Ребусны

*И Л Ә К*

\+

*Ч И Л Ә К*

*К Ө Я Н Т Ә*

рәвешендә күчереп язабыз.

2 нче адым. Беренче караштан ук *К* = 1, *Ч* = 9, *Ө* = 0 һәм *И* > 5.

3 нче адым. *Ә* = *К* + *К* = 2 һәм *Т* = *Ә* + *Ә* = 4.

4 нче адым. *Л* № 5, чөнки *Н* № 0 (билгеле булганча, *Ө* = 0).

*Л* № 6, чөнки *Н* № 2 (билгеле булганча, *Ә* = 2).

*Л* № 7, чөнки *Н* № 4 (билгеле булганча, *Т* = 4).

Димәк, *Л* яки 3, яки 8 генә була ала. Ләкин бу ике очракта да *Н* = 6.

5 нче адым. *И* яки 7, яки 8 генә була ала.

*Я* хәрефенә туры килгән цифрны ачыклау өчен җәдвәл төзибез:

Җәдвәлдән (*И* + *И*) юлы төшеп кала, чөнки *Т* = 4 һәм *Н* = 6. Моннан, *Л* № 3. Димәк, *Л* = 8.

Шулай итеп, *И* = 7 һәм *Я* = 5.

*6 нчы адым.* Нәтиҗәдә мондый чишелеш табыла:

7 8 2 1

\+

9 7 8 2 1

1 0 5 6 4 2.

*Җавабы*: 7821 + 97821 = 105642.

**Кая очасыз, казлар?**

*Җавабы*: Каз көтүе Җир шарының Төньяк (магнит) котыбына барып чыгачак.

**Эшлекле булсаң...**

*Чишү ысулы*:

*1 нче адым. УЧАК* дүрт урынлы сан икәнен исәпкә алганда, *УТ* кимендә 32 булырга тиеш.

*2 нче адым.* Шул ук вакытта *УТ* һәм *УЧАК* саннарының беренче цифрлары *У* хәрефе белән билгеләнгән. *УТ* санын квадратка күтәргәч, нәтиҗәдәге санның беренче цифры *У* булу шарты бары тик *У* = 9 очрагында гына үтәлә. Моны күңелдән бик җиңел юл белән исбатлап була: $30^2 = 900$ (өч урынлы сан), $40^2$ = =1600, $50^2 = 2500$, $60^2 = 3600$, $70^2 = 4900$, $80^2 = 6400$, $90^2 = 8100$ һәм $100^2 = 10000$ (биш урынлы сан).

*3 нче адым. Т* һәм *К* хәрефләре төрле цифрларны биләп торганга күрә, *Т* хәрефе урынына {2, 3, 4, 7, 8, 9} күплегенең бер цифры куелырга мөмкин. Ләкин *У* = 9 инде, димәк, *Т* № 9. Моннан, *УТ* яки 92, яки 93, яки 94, яки 97, яки 98 булырга мөмкин. Бу саннарның квадратлары:

$92^2 = 8464$, $93^2 = 8649$, $94^2 = 8836$, $97^2 = 9409$, $98^2 = 9604$.

Шушы саннар арасында *У* = 8 башланганнары мәсьәләнең шартларына туры килми.

*УТ* = 97 саны да мәсьәләнең шартларына каршы килә, чөнки *УЧАК* = 9409 санында беренче һәм соңгы цифрлар төрле булырга тиеш.

*Җавабы*: Мәсьәләнең бердәнбер чишелеше бар: $98^2 = 9604$.

**Ребусларны ничек төзиләр?**

*Чишү ысулы*:

*1 нче адым.* Ребусны күчереп язабыз:

*Т*

*А Т*

\+ *Ш А Т*

*А Ш А Т*
*Р А Ш А Т*

3 0 0 0 0.

Ребустан күренгәнчә, *Р* № 0, *А* № 0, *Ш* № 0 һәм *Т* № 0.

*2 нче адым.* Барлык мөмкин булган хисаплауларны җәдвәлләргә туплыйбыз:

*1.1 нче җәдвәл*

«*Т*» хәрефенә бәйле хисаплаулар

*2.1 нче җәдвәл*

Дүртенче баганада торучы «*А*» хәрефенә бәйле хисаплаулар (1.1 нче җәдвәл буенча истә калдырылган дистәләр
исәпкә алына)

*3.1 нче җәдвәл*

«*Ш*» хәрефенә бәйле хисаплаулар
(2.1 нче җәдвәл буенча истә калдырылган дистәләр
исәпкә алына)

*4.1 нче җәдвәл*

Икенче баганада торучы «*А*» хәрефенә бәйле хисаплаулар

(3.1 нче җәдвәл буенча истә калдырылган дистәләр
исәпкә алына)

*5.1 нче җәдвәл*
«*Р*» хәрефенә бәйле хисаплаулар
(4.1 нче җәдвәл буенча истә калдырылган дистәләр
исәпкә алына)

*3 нче адым.* Чишелешләрне эзләү өчен яраклы нәтиҗәләрне җәдвәлләрдән аерып күрсәтәбез:

*1.2 нче җәдвәл* (1.1 нче җәдвәл буенча)

*2.2 нче җәдвәл* (2.1 нче җәдвәл буенча)

*3.2 нче җәдвәл* (3.1 нче җәдвәл буенча)

*4.2 нче җәдвәл* (4.1 нче җәдвәл буенча)

*5.2 нче җәдвәл* (5.1 нче җәдвәл буенча)

*4 нче адым.* Җәдвәлләрдә тупланган мәгълүматлар бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә торалар.

Мәсәлән, 1.2 нче җәдвәлне исәпкә алу нәтиҗәсендә 2.2 нче җәдвәлдән (*А* ґ 4) юлы төшеп кала. Димәк, *А* № 5. Үз чиратында, 1.2 нче җәдвәлдә *Т* № 2 һәм *А* № 6, чөнки 2.2 нче җәдвәлдә бу цифрларга яраклы юллар юк.

2.2 нче җәдвәлне 4.2 нче җәдвәл белән чагыштырабыз. Нәтиҗәдә, *А* № 2 һәм *А* № 7 булганга күрә, 2.2 нче җәдвәлдән (*А* ґ 4 + 2) юлы төшеп кала. Димәк, 1.2 нче җәдвәлгә кире кайтканда, *Т* № 4. Шулай итеп, *Т* = 8.

3.2 нче җәдвәлдән (*Ш* ґ 3 + 1) һәм (*Ш* ґ 3 + 3) юллары төшеп кала, яки *Ш* № 3 һәм *Ш* № 9.

4.2 нче җәдвәлдә (*А* ґ 2 + 1) юлы юк. Димәк, 3.2 нче җәдвәл буенча *Ш* № 2. Моннан, *Ш* = 6. Шулай булгач, 2.2 нче җәдвәлдән *А* = 4.

Димәк, 5.2 нче җәдвәлдә бары тик (*Р* + 1) юлы гына кала. Моннан, *Р* = 2.

*Җавабы*:

8
4 8
\+ 6 4 8
4 6 4 8
2 4 6 4 8
―――――
3 0 0 0 0.

**Конструктор карга**

*Чишү ысулы*:

*1 нче адым.* Саннарны баганалап тапкырлыйбыз:

*ЧАБА*
ґ
*АК*

*КАРГА*.

Күренгәнчә, *Ч* № 0, *А* № 0 һәм *К* № 0.

*2 нче адым. А* цифрын *К* цифрына тапкырлаудан чыккан санның соңгы цифры *А* булырга тиеш. Моны түбәндәге тапкырлау җәдвәленнән аныклау җиңел. Шартлар үтәлгән очраклар җәдвәлдә ак төс белән аерылган.

Шул ук вакытта цифрлар квадратын тәшкил иткән саннар төшерелеп калдырыла (чөнки *А* № *К*). Шуннан чыгып, җәдвәлдәге мәгълүматларны яңартырга була.

*3 нче адым.* Гамәлдә мөмкин булган иң кечкенә саннар: *ЧАБА* = 1202, *АК* = 21 һәм шартлы рәвештә (бер үк цифр берничә хәрефне билгеләгән очракта да) *КАРГА* і 25242. Моннан, *К* № 1.

Җәдвәлдәге мәгълүматларны яңартабыз.

*4 нче адым.* Калган алты варианттан, цифрларны гамәлдәге хәрефләр урынына куеп карап, чишелешне табабыз.

*Җавабы*: 1404 ґ 46 = 64584 болт.

**Бас, кызым Әпипә!**

*Чишү ысулы*:

*1 нче адым.* Ребусны баганалап язабыз:

*Б А С*

\+

*К Ы З Ы М*

__________

*Ә П И П Ә.*

*2 нче адым. КЫЗЫМ* сүзенең икенче урында торучы *Ы* хәрефе 9 га тиң (*Ы* = 9). Моннан, *П* = 0.

*3 нче адым.* Язмага ачыкланган цифрларны куеп, язманы яңартабыз:

*Б А С*

\+

*К* 9 *З* 9 *М*

________

*Ә* 0 *И* 0 *Ә.*

*4 нче адым. А* № 0, чөнки *П* = 0. Димәк, *А* = 1. Шулай итеп,

*Б* 1 *С*

\+

*К* 9 *З* 9 *М*

________

*Ә* 0 *И* 0 *Ә.*

Ринат Гали улы Нуруллин 1954 елның 20 августында Татарстан Республикасының Балык Бистәсе районы Зур Мәшләк авылында дөньяга килә.

1972–1977 елларда Казан авыл хуҗалыгы институтында белем ала.

Хәрби хезмәттән кайткач, Татарстанның Мелиорация һәм су хуҗалыгы министрлыгында, СССР Фәннәр академиясенең Казан физика һәм техника институтында, Казан химия технологиясе институтында эшли. 1991 елда Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясенә укыту эшенә күчә, тулысы белән фәнгә чума.

1994 елда Ринат Нуруллин «Татарстан Республикасының атказанган уйлап табучысы» дигән исемгә лаек була. Бүгенге көндә ул — Казан дәүләт энергетика университеты доценты, техник фәннәр кандидаты. Аның 150 гә якын уйлап табу, фәнни һәм әдәби хезмәтләре бар.

Р.Нуруллин балалар өчен шигырьләр дә яза. Алар гади шигырьләр генә түгел. Алар үзенчәлекле, мавыктыргыч логик башваткычлар рәвешендә бирелгәннәр; уйлап эш итәргә өйрәтәләр, зирәклекне арттыралар.

Ринат Нуруллинның 2004 елда Татарстан китап нәшриятында «Өч бүре һәм өч сарык» исемле китабы дөнья күрде.

**ЭЧТӘЛЕК**


Автордан .....................................
Җиде туган-тумача ..............................
Исемем искитәрлек! .............................
Чабышмак табышмаклар ..........................
Тәлинкәле әкәмәт ...............................
Район исеме .................................
Сүз боткасы ..................................
Туңдырма ...................................
Бүрәнкә бәясе ................................
Шөгыль .....................................
Җәйнең кибән очы ...............................
Әти кызы ....................................
Альпинист үрмәкүчләр ............................
Борча һәм борыч ...............................
Бакалар кала сала ..............................
Ташны кая ташларга? ............................
Алма аша, алмашып .............................
Татлы йөк ...................................
Эт төше .....................................
Озынборын оныклары ............................
Робот ясыйм дисәң... .............................
Профессор чәүкә ...............................
Ухалыкмы балык? ...............................
Ни бәядә? ...................................
Кашык бушмы ...............................
Бер айга ел сыямы? ..............................
Бер олау сорау .................................
Хат ташучы көнгерә ..............................
ӘҮ! ........................................
Суперребус ..................................
Иләк, чиләк һәм көянтә ..........................
Кая очасыз, казлар? .............................
Эшлекле булсаң ...............................
Ребусларны ничек төзиләр? ........................
Конструктор карга ...............................
Бас, кызым Әпипә! ..............................
Кырык карак әкияте ..............................
Чәүкә кунган түбәгә ..............................
Маймыл ярата банан .............................

Хисмәтнең хикмәтләре ...........................

Чатан пират ..................................
Ертык юрган ..................................
Яшел бүкән ..................................
Карбыз кыры .................................

Чишү ысуллары һәм җаваплар .......................

Литературно-художественное издание

**Нуруллин** Ринат
(**Нуруллин** Риннат Галеевич)

**ПАУКИ-АЛЬПИНИСТЫ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2008

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Нуруллин** Ринат
(**Нуруллин** Риннат Гали улы)

**АЛЬПИНИСТ ҮРМӘКҮЧЛӘР**

Мөхәррире *Л.М.Шәехов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 5.05.2008. Форматы 70г100$^1/_{16}$.
Шартлы басма табагы 7,15 + форз.0,33. Шартлы буяу-оттиск 29,58.
Нәшер-хисап табагы 3,70 + форз.0,53. Тиражы 5000 д. Заказ Т-488.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

http://tatkniga.ru
E-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.